КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 июль г.Казань № 618

«Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – Программа) расларга.
2. Дәүләт заказчысы – Программаның координаторы итеп Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгын билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ел саен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда, мөмкинлекләрне исәпкә алып, һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге максатларга җибәрелә торган акча чикләрендә Программа чараларын гамәлгә ашыруга акча күздә тотарга.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.
5. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин